КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 июль г.Казань № 603

«Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында

Дәүләт идарәсе, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә цифрлы технологияләрне нәтиҗәле үстерүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының «Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – мәгълүмат системасы) булдыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Бу карарга теркәлгән «Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне расларга.

3. «Татарстан Республикасы Цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесен мәгълүмат системасының дәүләт заказчысы итеп билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 17 июль, 603 нче
карары белән расланды

«Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы»
Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә «Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшләвен оештыру тәртибен билгели.

1.2. «Клиентлаштырылган цифрлы хезмәтләр күрсәтүнең бүленгән архитектурасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Платформа) – программа-аппарат чаралары комплексы, шулай ук бертип программа компонентлары, шул исәптән электрон исәпләү машиналары өчен программалар, мәгълүмат системалары һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) Платформаны кулланышка кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән файдалану принципларына һәм үзара хезмәттәшлекнең стандартлаштырылган интерфейсларына ия булган сайтлар.

## II. Платформаны булдыру максатлары

2.1. Платформа түбәндәге максатларда булдыра:

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында дәүләт, муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә һәм функцияләрне башкарганда цифрлы технологияләрне алга таба үстерү;

Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын алып бару һәм аларның инфраструктурасы чыгымнарын оптимальләштерү;

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында процессларның нәтиҗәлелеген арттыру һәм сыйфатын яхшырту;

гамәлдәге һәм яңа булдырыла торган мәгълүмат системаларында эшкәртелә торган мәгълүматларны максималь нәтиҗәле куллану;

яңа булдырыла торган мәгълүмат системаларында шәхси һәм файдаланылуы чикләнгән башка мәгълүматларны эшкәрткәндә аларның иминлеген тәэмин итү;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өлешендә гражданнарга хезмәт күрсәтүнең мультиканаллы сценариен тәэмин итү.

## III. Платформаның бурычлары

3.1. Татарстан Республикасында дәүләт, муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм функцияләрне башкару барышларын автоматлаштыру һәм цифрлаштыру, кәгазь чыганаклардагы мәгълүматны әйләнештә йөртүне минимальләштерү.

3.2. Төрле мәгълүмат системаларының үзара интеграцияләнүен тәэмин итү, мәгълүматны «бер тапкыр кертү һәм күп тапкыр куллану» принцибы буенча куллану.

3.3. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гражданнар тарафыннан кәгазь чыганакта бирелә торган мәгълүматның күләмен минимальләштерү.

3.4. Татарстан Республикасында дәүләт, муниципаль хезмәтләрне һәм функцияләрне сыйфатлы һәм микъдари куллануны анализлау инструментларын бирү.

3.5. Әлеге бурычларны үтәү өчен Платформа гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләрен эшләүгә һәм җәелдерүгә карата стандартлаштырылган чараларны һәм алымнарны тәэмин итә.

## IV. Платформаның составы

4.1. Платформа бер-берсе белән үзара бәйләнышларга керә торган берничә дәрәҗәдән тора:

инфраструктура дәрәҗәсе: серверлар, мәгълүматларны саклау системалары, челтәр җиһазлары һәм башка җайланмалар, шулай ук әлеге аппарат чараларының эшләвен тәэмин итә торган операцион системалар. Бу дәрәҗәсе виртуальләштерелергә мөмкин;

технологик дәрәҗә: билгеле бер предмет өлкәсенә бәйләнмәгән бертип программа компонентлары, мәсәлән: мәгълүматлар базалары белән идарә итү системалары, объект саклагычлары, программаны баланслаштыручылар, хәбәрләр брокерлары һәм башка техник чаралар. Әлеге компонентларны җәелдерү һәм үтәү өчен инфраструктура дәрәҗәсе кулланыла;

гамәли дәрәҗә: программа компонентлары, шул исәптән мәгълүмат системалары, электрон исәпләү машиналары өчен программалар һәм «Интернет»челтәрендәге сайтлар. Бу дәрәҗә, үз чиратында, ике ярдәмче дәрәҗәгә бүленә:

гамәли дәрәҗәдәге гомуми компонентлар – төрле гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләрендә кабат кулланылырга мөмкин булган функциональ модульләр;

гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләре – мәгълүмат системалары, программа тәэминаты (шул исәптән электрон исәпләү машиналары өчен программалар һәм «Интернет» челтәрендәге сайтлар), шулай ук билгеле бер предмет (гамәли) өлкәсен автоматлаштыра торган мәгълүмат системалары, программа тәэминаты.

4.2. Гамәли дәрәҗәдәге гомуми компонентлар һәм Платформа составына керә торган гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләре исемлеге, шулай ук аларның эш регламентлары, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән килештереп, Платформа операторы тарафыннан раслана.

4.3. Тәэмин итү конвейеры: программа тәэминатын эшләү һәм аны Платформаның гамәли дәрәҗәсенә җәелдерү процессларын тәэмин итә торган программа компонентлары җыелмасы (шул исәптән башлангыч кодны саклауны һәм продуктив мохиткә эшчәнлеген чыгаруны кертеп).

4.4. Идарә итү һәм күзәтү дәрәҗәсе: инфраструктура дәрәҗәсе, технологик дәрәҗә, кушымталарның гамәли дәрәҗәдә үтәлеше белән идарә итү, шулай ук Платформаның барлык компонентлары эшләвенең агымдагы статусын күзәтү өчен программа чаралары җыелмасы.

## V. Платформа белән үзара хезмәттәшлек итү

5.1. Платформа белән үзара хезмәттәшлекне түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

Дәүләт заказчысы – эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштырганда Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучы булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы яки дәүләт учреждениесе;

Платформа операторы – Платформаны эксплуатацияләү, шул исәптән аның мәгълүматлар базасындагы мәгълүматны эшкәртү эшчәнлеген оештыра һәм гамәлгә ашыра торган, шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатларын, эшкәртелергә тиешле шәхси мәгълүматлар составын, шәхси мәгълүматлар белән башкарыла торган гамәлләрне (операцияләрне) билгели торган дәүләт хакимиятенең башкарма органы, яки аның тарафыннан оештырылган дәүләт учреждениесе, яки Платформа операторы яки Дәүләт заказчысы белән шартнамә нигезендә башка оешма;

Платформаның техник операторы – Платформаны булдыру, үстерү һәм техник яктан ярдәм итү чараларын үткәрүне, Платформада эшкәртелә торган мәгълүматны техник яктан саклауны тәэмин итүче, мәгълүмати алмашуда катнашучыларга техник файдалану мөмкинлеген бирүче һәм Платформа операторының сораулары нигезендә Платформаны мәгълүмат алмашуда катнашучыларның мәгълүмат системалары белән техник интеграцияләүне гамәлгә ашыручы, шулай ук бу Нигезләмә нигезендә башка вазыйфаларны башкаручы оешма; әгәр дә техник оператор(-лар) билгеләнмәгән булса, аның (аларның) функцияләре Платформа операторы тарафыннан гамәлгә ашырыла;

мәгълүмат технологияләре эшләнмәләре белән тәэмин итүчеләр – Платформа операторы тарафыннан билгеләнгән техник сәясәтләргә туры китереп, гамәли системаларны һәм мәгълүмат технологияләре эшләнмәләрен эшләүне һәм Платформага урнаштыруны тәэмин итүче оешмалар;

Функциональ кулланучы – Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт (муниципаль) хезмәтләре күрсәтү максатларында Платформа операторы белән килешү нигезендә башка оешмалар;

Гариза бирүчеләр – Платформа кысаларында эшли торган гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләрен кулланучы гражданнар һәм оешмалар.

## VI. Платформадан файдалану мөмкинлеге

6.1. Платформадан файдалану мөмкинлеге Платформаның спецификациясе, шулай ук Платформа составына керә торган гамәли мәгълүмат технологияләре

эшләнмәләре спецификацияләре белән билгеләнә торган бурычларны бүлү һәм вәкаләтләрне минимальләштерү принцибы буенча, рольләр системасы нигезендә аутентификацияләү һәм авторизацияләү чараларын кулланып тормышка ашырылды.

## VII. Платформаның эшләвен тәэмин итүче оешмаларның бурычлары

7.1. Дәүләт заказчысы түбәндәгеләргә бурычлы:

Платформаны һәм аның аерым гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләрен эшләү, шулай ук булдыру буенча, аларга техник ярдәм күрсәтү, аларны модернизацияләү буенча эшләр (хезмәтләр) һәм Платформага һәм (яки) аның аерым элементларына карата башка эшләр (хезмәтләр) башкару (күрсәтү) максатларында билгеләнгән тәртиптә подрядчыларны (башкаручыларны) билгеләргә;

подрядчылар (башкаручылар) белән дәүләт контрактлары төзергә;

Платформаны һәм аның аерым гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләрен эшләү, шулай ук булдыру, Платформага һәм (яки) аның аерым элементларына карата техник ярдәм күрсәтү, модернизацияләү һәм башка эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) чараларын финанслауны; мәгълүматны саклау буенча таләпләр эшләүне тәэмин итәргә.

7.2. Платформа операторы түбәндәгеләргә бурычлы:

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән килештереп, гамәли дәрәҗәдәге гомуми компонентлар һәм Платформа составына керә торган гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләре исемлеген, шулай ук аларның эш регламентларын расларга;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән килештереп, Платформаның техник операторын билгеләргә;

Платформага эксплуатацияләү документларын эшләргә;

Дәүләт заказчысы тарафыннан бүлеп бирелгән ресурслар кысаларында Платформаны проектлаштыруны һәм үстерүне тәэмин итәргә;

Платформада һәм аның составына керә торган гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләрендә урнаштырыла торган белешмәләр, мәгълүматлар һәм электрон документлар формаларын һәм форматларын билгеләргә;

Платформадан һәм аның составына керә торган гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләреннән файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа, лингвистик, хокукый һәм оештыру чараларына карата таләпләрне, шул исәптән аның архитектурасына карата таләпләрне билгеләргә;

тәэмин итүчеләрнең Платформадагы һәм аның составына керә торган гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләре мәгълүматлары белән мәгълүмат алмашу тәртибен билгеләргә;

Платформа архитектурасын проектлаштыруны, мәгълүмат технологияләре эшләнмәләре белән тәэмин итүчеләр тарафыннан гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләрен һәм архитектура эшләнмәләрен эшләү белән җитәкчелек итүне гамәлгә ашырырга, шулай ук эшләнелә торган һәм гамәлгә кертелә торган гамәли мәгълүмат

технологияләре эшләнмәләрендә архитектура эшләнмәләрен тормышка ашыруны тикшерүдә тотарга.

7.3. Платформаның техник операторы түбәндәгеләргә бурычлы:

Платформада эшкәртелә торган мәгълүматны саклау һәм Платформаны булдыру, үстерү һәм техник яктан тәэмин итү чараларын үткәрүне тәэмин итәргә;

Платформа составына керә торган аның барлык дәрәҗәләренең тотрыклы һәм өзлексез эшләвен тәэмин итәргә;

регламент эшләре турында Платформа операторына, мәгълүмат алмашуда катнашучыларга һәм функциональ кулланучыларга аларны үткәргәнгә кадәр ике көннән дә соңга калмыйча хәбәр итеп, Платформаның һәм аның составына керә торган гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләренең техник һәм программа эшчәнлеген тәэмин итәргә;

Платформада шәхси мәгълүматларны эшкәрткәндә аларның конфиденциальлеге сакланышын һәм аларның иминлеген тәэмин итәргә;

Платформадагы һәм аның составына керә торган гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләрендәге мәгълүматны һәм шәхси мәгълүматларны саклауны тәэмин итәргә, шул исәптән дәүләт мәгълүмат системаларына карата законнар таләпләре нигезендә аларны саклау буенча оештыру һәм техник чаралар күрергә;

Платформага һәм аның составына керә торган гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләренә ярдәм күрсәтү хезмәтен оештыруны һәм аның эшчәнлеген тәэмин итәргә (бу функцияне тормышка ашыру өчен Платформаның техник операторы подрядчы оешмаларны җәлеп итәргә мөмкин);

Платформа операторының сораулары нигезендә мәгълүмати алмашуда катнашучыларга техник мөмкинлекләр бирергә;

Платформа операторының сораулары нигезендә Платформаны мәгълүмати алмашуда катнашучыларның мәгълүмат системалары белән техник интеграцияләүне гамәлгә ашырырга;

Платформа операторының күрсәтмәләрен аның сораулары нигезендә бу Нигезләмә белән билгеләнгән вазыйфалар чикләрендә башкарырга;

Платформа һәм аның составына керә торган аерым элементларның эшләвен тәэмин итә торган сервер һәм челтәр җиһазларының өзлексез эшләвен тәэмин итәргә;

функциональ кулланучылар өчен методик материалларны актуальләштерергә.

7.4. Мәгълүмат технологияләре эшләнмәләре белән тәэмин итүчеләр түбәндәгеләргә бурычлы:

Платформаның гамәли программа компонентларын эшләү һәм кайтарту өлешендә Платформа операторы тарафыннан билгеләнгән регламентларны һәм методологияне үтәргә;

эшләнелә торган программа компонентларының Платформа өчен Платформа операторы тарафыннан билгеләнгән агымдагы таләпләргә, архитектура принципларына һәм чикләүләргә туры килүен тәэмин итәргә;

гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләрен проектлаштырганда һәм эшләгәндә мәгълүмати иминлек таләпләрен тормышка ашыруны тәэмин итәргә;

Дәүләт заказчысы белән контрактларда билгеләнгән вакытлар кысаларында һәм шартларда әлеге таләпләргә туры килмәүне һәм эшчәнлектәге хаталарны бетерергә;

Платформа составына керә торган гамәли мәгълүмат технологияләре эшләнмәләренә эксплуатация документларын эшләргә.

## VIII. Мәгълүмати иминлекне тәэмин итү

8.1. Платформаның мәгълүмати иминлеген тәэмин итү «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны саклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Платформа кысаларында мәгълүмати иминлекне – рөхсәт ителмәгән файдаланудан, саклана һәм тапшырыла торган мәгълүматның бөтенлеген һәм дөреслеген бозудан саклауны тәэмин итү чаралары комплексы карала.

Платформада мәгълүматны саклау аның программа-техник чаралары комплексы һәм Платформада эшләү таләпләрен үтәү буенча оештыру чаралары ярдәмендә тәэмин ителә.

Платформаның мәгълүмат алмашуда катнашучылар белән мәгълүмати һәм технологик хезмәттәшлеге аларны программа инфраструктурасы һәм технологик инфраструктура ярдәмендә интеграцияләү, мәгълүмат алмашуда катнашучылар белән Платформа операторы арасында мәгълүматлар алмашуның килештерелгән форматлары нигезендә сораулар җибәрү һәм җаваплар алу юлы белән гамәлгә ашырыла.